| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Кулегашского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Күләгәш авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2018 Күләгәш авылы № 43-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 сентябрендәге 40-1 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында»

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 августындагы 340-ФЗ номерлы Федераль законына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге Уставына туры китереп, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге Советы карар бирде :

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 сентябрендәге 40-1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1,6 пунктның 100 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«техник заказчы - төзүче тарафыннан вәкаләт бирелгән һәм төзүче исеменнән инженерлык эзләнүләрен үтәү турында, проект документларын әзерләү, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, сүтү турында килешүләр төзи торган юридик зат әлеге эш төрләрен башкаруга биремнәр әзерләү, инженерлык эзләнүләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүне, төзелеш, реконструкцияләүне, капиталь ремонт, капиталь төзелеш объектларын сүтеп ташлый торган затларга, әлеге төр эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар һәм документлар бирү, проект документларын раслау, капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт алу өчен кирәкле документларны имзалау, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарда каралган башка функцияләрне гамәлгә ашыру (алга таба - техник заказчы функцияләре). Техник заказчының функцияләре Шәһәр

Төзелеше Кодексының 47 статьяның 2.1 өлешендә, 48 статьяның 4.1 өлешендә, 52 статьяның 2.1 һәм 2.2 өлешләрендә, 55.31 статьясының 5 һәм 6 өлешләрендә каралган очраклардан тыш, бары тик инженерлык эзләнүләр, архитектура-төзелеш проектлаштыру, төзелеш, реконструкция, капиталь ремонт, капиталь төзелеш объектларын сүтү өлкәсендә үзеннән-үзе көйләнә торган оешма әгъзасы тарафынннна гына башкарылырга мөмкин;»

2. Әлеге Карарны Күләгәш авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе Ю.Н. ВАСИЛЬЕВ